# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фондына кертемнәрнең 1996 елга иминлек тарифы турында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1 статья. Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фондына кертемнәрнең 1996 елга иминлек тарифын төрле яклап исәпләнелгән хезмәт өчен түләүгә карата түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр һәм хуҗалык итүче башка субъектлар өчен - ике процент;

колхозлар, совхозлар һәм авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү белән шөгыльләнүче башка предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләр өчен - бер процент.

2 статья. Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт фондына иминлек кертемнәре түләүдән түбәндәгеләрне азат итәргә:

- Татарстан Республикасының Ветераннар оешмалары советын, инвалидларның иҗтимагый оешмаларын, дини берләшмәләрне, барлык керемнәрен уставларында каралган максатларны гамәлгә ашыру өчен файдаланучы һәм әлеге иҗтимагый һәм дини берләшмәләр милкендәге предприятиеләрне, берләшмәләрне һәм учреждениеләрне, шулай ук барлык хезмәткәрләрнең кимендә 50 процентын инвалидлар тәшкил итүче предприятиеләрне, оешмаларны һәм учреждениеләрне;

- хәрби частьләрне, хәрби-уку йортларын, Россия Федерациясенең Оборона министрлыгы предприятиеләрен һәм оешмаларын, Татарстан Республикасының Дәүләт иминлеге комитетын, Татарстан Республикасының Эчке эшләр министрлыгын, аның җинаять-башкарма системасындагы бүлекчәләрен, моңа аларның Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджетларыннан финансланучы хуҗалык исәбендәге төзелмәләрен; шулай ук гражданнарга һәм оешмаларга хокукый ярдәм күрсәткән өчен юридик консультацияләргә кергән һәм алар тарафыннан күчерелә торган акчадан Адвокатлар коллегиясен; Акыл милкенең Татарстан агентлыгын (ТАИСны) авторлык гонорарлары суммасыннан.

3 статья. Күрсәтелгән средстволарның вакытында һәм тулысынча күчерелүен, аларның дөрес һәм максатчыл файдаланылуын тикшереп торуны Татарстан Республикасының Дәүләт салым хезмәте һәм Татарстан Республикасының банк учреждениеләре белән берлектә Татарстан Республикасының Хезмәт һәм җәмгыяви мәсьәләләр буенча дәүләт комитетына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Парламент контроле комитетына йөкләргә.

4 статья. Әлеге Законны 1996 елның 1 гыйнвареннан гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1996 елның 6 марты
N 465